**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Чыбыклы авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 114** **28.02.2024г.**

**Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 маендагы 94 номерлы «Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары нигезендә территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпке алуны тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары; «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советы

**КАКРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 маендагы 94 номерлы «Чыбыклы авыл территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәглүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәглүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.Н. Гадершин**